ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮГАРЫ ОСЛАН
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

01.08.2019 с. Верхний Услон 720

Татарстан Республикасы
Югары Ослан муниципаль районында
2019-2020 уку елында
гражданнарны хәрби хезмәткә
әзерләү турында

«Россия Федерациясе гражданнарын хәрби хезмәткә әзерләү турында Нигезләмәне раслау хакында» 1999 елның 31 декабрендәге №1441 Россия Федерациясе Хөкүмәте карарын үтәү һәм гражданнарны хәрби-учет белгечлекләре буенча хәрби хезмәткә әзерләүне камилләштерү максатларында Югары Ослан муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Расларга:

1.1. Югары Ослан муниципаль районында 2019-2020 уку елында хәрби-учет белгечлекләре буенча әзерлек буенча төп чаралар планы (Кушымта № 1).

1.2. 2019-2020 уку елына Югары Ослан муниципаль районы мәгариф учреждениеләрендә Тормыш иминлеге нигезләре классларының һәм укыту-матди базасының комплектлылыгын тикшерү буенча комиссия составы (Кушымта № 2).

1.3. Россия Федерациясе Кораллы Көчләре өчен белгечләр әзерләүне контрольдә тоту комиссиясе составы (Кушымта № 3).

2. Югары Ослан муниципаль районының «Мәгариф бүлеге» МКУ тәкъдим итәргә:

- «Хәрби хезмәт нигезләре» курсы укытучыларын методик әзерләүне яхшырту буенча эш алып барырга, запастагы офицерлардан, югары яки урта хәрби белемгә ия булган белем бирү учреждениеләрен һәм уку пунктын комплектларга;

- белем бирү учреждениеләренең укыту-матди базасын һәм уку пунктының уку-укыту базасын камилләштерергә, хәрби хезмәткә чакырылуга кадәрге яшьләр белән хәрби хезмәт нигезләре дәресләре үткәрү өчен мәгариф учреждениеләренең спорт залларын актив кулланырга;

- яшьләрне хәрби-патриотик әзерләү эшен көчәйтергә, сугыш һәм кораллы конфликтлар ветераннары, Кораллы Көчләр офицерлары һәм хәрби хезмәткәрләре, Россия Армиясе сафларында хезмәт итүне пропагандалау буенча хәрби уку йортлары курсантлары белән очрашуларны киңрәк кулланырга.

3. Татарстан Республикасы Югары Ослан районы хәрби комиссарына Татарстан Республикасы Хәрби комиссариатының Россия Федерациясе Кораллы Көчләре өчен белгечләр әзерләү буенча нарядны (хисап биремен) вакытында һәм сыйфатлы башкаруны тәэмин итәргә тәкъдим итәргә.

4. Учреждение, оешма җитәкчеләренә хәрби хезмәткә алынучыларга уку чорында айлык хезмәт хакының 50% (Татарстан Республикасында билгеләнгән

минималь хезмәт хакы күләменең яртысыннан да ким булмаган), уку урынына бару һәм кире кайту бәясен, шулай ук торак яллау чыгымнарын түләргә тәкъдим итәргә. Уку чорында хәрби хезмәткә чакырылучының элек биләгән вазыйфасын саклап калырга.

5. Югары Ослан районы халыкны эш белән тәэмин итү үзәге дәүләт бюджет учреждениесенә:

вакытлыча эшләми торган, билгеләнгән тәртиптә эшсез дип танылган хәрби хезмәткә чакырылучылар арасыннан гражданнарны хәрби-учет белгечлекләре буенча әзерләүгә җибәрергә.

6. Татарстан Республикасы Югары Ослан районы хәрби комиссары, Югары Ослан муниципаль районы Мәгариф бүлеге башлыгы, Яшьләр эшләре һәм спорт бүлеге башлыгына:

- эшчәнлеге Россия Федерациясе территориясендә рөхсәт ителгән иҗтимагый берләшмәләр белән берлектә төп һәм урта гомуми белем бирү учреждениеләрендә, шулай ук хәрби-патриотик, яшьләр һәм балалар берләшмәләрендә гражданнарны хәрби-патриотик тәрбияләү эшен оештырырга;

- спортның хәрби-гамәли төрләрен пропагандалау, оборона-спорт чараларын үткәрү, спортның хәрби-гамәли һәм техник төрләре буенча яңа түгәрәкләр һәм секцияләр ачу буенча эш алып барырга.

7. «Югары Ослан район үзәк хастаханәсе» ДАССО баш табибына оештырырга:

- гражданнарны хәрби исәпкә куелганчы һәм аннан соң беренчел медицина тикшерүләре;

- гражданнарны беренчел исәпкә куелганчы һәм аннан соң, шулай ук хәрби хезмәткә чакырылган гражданнарны вакытлыча хәрби хезмәткә яраксыз дип танылганнан соң диспансер күзәтүе һәм дәвалавы;

- хәрби-учет белгечлекләре буенча уку өчен районның хәрби комиссариат юнәлеше буенча гражданнарга медицина тикшерүләре үткәрү.

8. Татарстан Республикасы Югары Ослан районы хәрби комиссарына әлеге карарның үтәлеше турында мәгълүматны Югары Ослан муниципаль районы Башкарма комитетына 2020 елның 20 августына тапшырырга.

9. Әлеге карарның үтәлешен үзем контрольдә тотам.

Башкарма комитет җитәкчесе                                        В.С. Тимиряев

Югары Ослан муниципаль районы
Башкарма комитет җитәкчесенең
01.08.2019, № 720 карарына
Кушымта № 1

Югары Ослан муниципаль районында 2019-2020 уку елында гражданнарны хәрби-учет белгечлекләре буенча әзерләү буенча төп чаралар
ПЛАНЫ

| № | Чара исеме | Җаваплы башкаручы | Үткәрү вакыты | Үтәлеш турында билге |
|---|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 |
| Оештыру чаралары | | | | |
| 1. | Югары Ослан муниципаль районы Башкарма комитетының гражданнарны хәрби хезмәткә әзерләүгә йомгак ясау һәм яңа уку елына бурычлар билгеләү | Югары Ослан муниципаль районы Башкарма комитеты, хәрби комиссариат | 01.09.2019 елга кадәр | |
| 2. | Гражданнарны хәрби хезмәткә әзерләү мәсьәләләре буенча барлык кызыксынучы органнар һәм оешмалар җитәкчеләренең уку-методик киңәшмәсе һәм яңа уку елына бурычлар билгеләү. | «Югары Ослан муниципаль районы Мәгариф бүлеге» МКУ (алга таба текст буенча– Мәгариф бүлеге), Башкарма комитетның яшьләр эшләре һәм спорт бүлеге (алга таба – текст буенча-Яшьләр эшләре һәм спорт бүлеге), хәрби комиссариат | 01.09.2019 елга кадәр | |
| 3. | Төп планлаштыручы документлар әзерләү:<br>- Югары Ослан муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең гражданнарны хәрби хезмәткә әзерләү мәсьәләләре турында карары проекты һәм әлеге әзерлек буенча төп чаралар планы;<br>- 2018-2019 уку елында гражданнарны хәрби хезмәткә әзерләү йомгаклары һәм 2019-2020 уку елына бурычлар турында хәрби комиссар боерыгы проекты. | хәрби комиссариат | 01.09.2019 елга кадәр.<br><br>01.09.2019 елга кадәр. | |
| Оборона өлкәсендә башлангыч белем алу | | | | |
| 1. | «Тормыш эшчәнлеге иминлеге | Мәгариф бүлеге, | уку елы | |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | нигезләре» курсын укыту өчен уку һәм күрсәтмә әсбаплар белән тәэмин итүдә мәгариф учреждениеләренә ярдәм күрсәтү. | хәрби комиссариат | дәвамында | |
| 2. | «Тормыш иминлеге нигезләре» курсы укытучылары белән укыту-методик җыеннар үткәрүне оештыру. | Мәгариф бүлеге, хәрби комиссариат | август | |
| 3. | Гражданнар тарафыннан башлангыч белем алуны һәм гомуми белем бирү учреждениеләрендә Гражданнар оборонасы буенча күнекмәләр алуны контрольдә тоту. | Мәгариф бүлеге | уку елы дәвамында | |
| Хәрби хезмәт нигезләре буенча гражданнарны әзерләү | | | | |
| 1. | «Хәрби хезмәт нигезләре» курсы укытучылары белән өч көнлек укыту-методик җыемнар үткәрү. | Мәгариф бүлеге, хәрби комиссариат | 29.08.2019 елга кадәр | |
| 2. | Гомуми белем бирү учреждениеләрендә хәрби хезмәт нигезләре буенча конкурслар үткәрү:<br>- укучыларның әзерлек дәрәҗәсе буенча иң яхшы класска;<br>- иң яхшы укыту-матди базага;<br>- патриотик юнәлештәге күрсәтмә агитация смотры. | Мәгариф бүлеге, хәрби комиссариат | 29.04.2020 елга кадәр | |
| 3. | Гомуми белем учреждениеләренең югары сыйныф укучылары белән «Хәрби хезмәт нигезләре» буенча биш көнлек уку-кыр җыеннары уздыру. | Мәгариф бүлеге, яшьләр эшләре һәм спорт бүлеге, хәрби комиссариат | май-июнь 2020 ел | |
| Гражданнарны хәрби-патриотик тәрбияләү | | | | |
| 1. | Гомуми белем бирү учреждениеләрендә Ватан тарихына багышланган батырлык дәресләре, сыйныфтан тыш чаралар үткәрү. | Мәгариф бүлеге | ел дәвамында | |
| 2. | Ватанны саклаучылар көненә һәм Җиңү көненә багышланган оборона-массакүләм һәм спорт эшләре айлыкларын үткәрү. | Мәгариф бүлеге, Яшьләр эшләре һәм спорт бүлеге, хәрби комиссариат | февраль май | |
| 3. | Ватанны саклаучылар көненә һәм Җиңү көненә багышланган оборона-массакүләм һәм спорт эшләре айлыкларын үткәрү. | Яшьләр эшләре һәм спорт бүлеге, хәрби комиссариат | октябрь, апрель | |
| 4. | Гомуми белем бирү учреждениеләрендә «Аҗаган» хәрби-патриотик уенын оештыру һәм уздыру. | Мәгариф бүлеге, Яшьләр эшләре һәм спорт бүлеге, хәрби комиссариат | февраль | |
| 5. | Хәрби хезмәткә чакырылучылар көнен үткәрү | Мәгариф бүлеге, Яшьләр эшләре | октябрь, апрель | |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | | һәм спорт бүлеге, хәрби комиссариат | | |
| Гражданнарны хәрби-учет белгечлекләре буенча әзерләү | | | | |
| 1. | Хәрби хезмәткә чакырылырга тиешле гражданнарны хәрби-учет белгечлекләре буенча ТР ДОСААФ белем бирү учреждениеләрендә хәрби исәпкә алу өчен сайлап алуны тәкъдим ителгән документларны, граждан белән әңгәмәләрне, медицина тикшеренүе нәтиҗәләрен һәм һөнәри психологик сайлап алуны өйрәнү нигезендә гражданнарны хәрби исәпкә кую комиссиясе эше барышында башкарыру. | Башкарма комитет, хәрби комиссариат | уку елы дәвамында, поток буенча укыту | |
| 2. | Татарстан Республикасы хәрби комиссариатыннан наряд алганда, гражданнарны хәрби-учет белгечлекләре буенча әзерләү һәм хәрби хезмәткә чакырылырга тиешле гражданнарны хәрби-учет белгечлекләре буенча әзерләү өчен, ТР ДОСААФ мәгариф учреждениеләрендә уку төркемнәрен комплектлаштыру. | | уку елы дәвамында, поток буенча укыту | |
| Медицина тикшеренүе һәм медицина тикшерүе | | | | |
| 1. | Хәрби хезмәткә чакырганда өстәмә медицина тикшерүе очракларын булдырмау максатларында беренчел аларны хәрби исәпкә кую һәм хәрби хезмәткә чакыру арасында булган авырулар буенча гражданнарны тулы медицина тикшерүен тәэмин итү. | «Югары Ослан район үзәк хастаханәсе» ДАССО | октябрь-декабрь, апрель-июль | |
| 2. | Тикшерүгә җибәрелгән гражданнарны контрольдә тоту. | хәрби комиссариат | октябрь-декабрь, апрель-июль | |
| Дәвалау-сәламәтләндерү эше | | | | |
| 1. | Профилактик медицина тикшерүләре уздыру һәм хәрби хезмәткә чакырылырга тиешле гражданнарны дәвалау. | Авыл җирлекләре, «Югары Ослан район үзәк хастаханәсе» ДАССО, хәрби комиссариат | сентябрь-апрель | |
| 2. | Гражданнарны беренчел хәрби исәпкә куелганчы, диспансер күзәтүен уздыруны, физик үсешне, шулай ук хәрби хезмәткә чакырылганда аларны вакытлыча | «Югары Ослан район үзәк хастаханәсе» ДАССО | ел дәвамында | |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | хәрби хезмәткә яраксыз дип танылган очракта контрольдә тоту. | | | |
| 3. | ТР РОГО ДОСААФ региональ белем бирү учреждениеләренә хәрби-учет белгечлекләре буенча әзерлеккә юнәлдерелгән гражданнар өчен медицина комиссияләре уздыру | «Югары Ослан район үзәк хастаханәсе» ДАССО | сентябрь, октябрь | |
| 4. | Наркология диспансерларында исәптә торучы хәрби хезмәткә алынучылар турында мәгълүматларны җыю һәм гомумиләштерү. | «Югары Ослан район үзәк хастаханәсе» ДАССО | сентябрь-июнь | |
| 5. | Гражданнарны хәрби исәпкә беренчел куйганда медицина тикшеренүе, медицина тикшерүе һәм дәвалау-сәламәтләндерү чаралары үткәрү. | «Югары Ослан район үзәк хастаханәсе» ДАССО | январь-март | |
| 6. | Хәрби белем бирү учреждениеләренә, Нахимов хәрби-диңгез училищеларына һәм кадет корпусларына керә торган гражданнар өчен медицина комиссияләре үткәрү. | «Югары Ослан район үзәк хастаханәсе» ДАССО | март-июнь | |
| Гражданнарны хәрби хезмәткә ирекле әзерләү | | | | |
| 1. | Россия Федерациясе Оборона министрлыгының хәрби белем бирү учреждениеләренә керү өчен кандидатларны сайлап алуны һәм җибәрүне оештыру. | хәрби комиссариат | март-май | |
| 2. | Кандидатларны туплау һәм аларны Нахимов хәрби-диңгез училищеларына һәм кадет корпусларына керү өчен җибәрү. | хәрби комиссариат | март-июнь | |
| Контроль һәм ярдәм күрсәтү | | | | |
| Тормыш иминлеге нигезләре классының һәм укыту-матди базаның комплектлылыгын тикшерү | | | | |
| 1. | МБГББУ «Югары Ослан гимназиясе» | Комиссия (Кушымта №2) | октябрь 2019ел | |
| 2. | МБГББУ «Олы Меми урта гомуми белем бирү мәктәбе» | Комиссия (Кушымта №2) | ноябрь 2019 ел | |
| 3. | МБГББУ «Матюшино урта гомуми белем бирү мәктәбе» | Комиссия (Кушымта №2) | декабрь 2019 ел | |
| 4. | МБГББУ «Карагуҗа урта гомуми белем бирү мәктәбе» | Комиссия (Кушымта №2) | январь 2020ел | |
| 5. | МБГББУ «Макыл урта гомуми белем бирү мәктәбе» | Комиссия (Кушымта №2) | февраль 2020 ел | |
| 6. | МБГББУ «Шиланга урта гомуми белем бирү мәктәбе» | Комиссия (Кушымта №2) | март 2020 ел | |

Башкарма комитетның эшләр идарәчесе А.К. Мингазова

Югары Ослан муниципаль районы
Башкарма комитет җитәкчесенең
01.08.2019, № 720 карарына
Кушымта № 2

Югары Ослан муниципаль районының белем бирү оешмаларында тормыш иминлеге нигезләре классларының һәм укыту-матди базасының комплектлылыгын тикшерү буенча 2019-2020 уку елына
Комиссия составы

Комиссия рәисе:

| | |
|---|---|
| Тимиряев Виктор Сергеевич | Югары Ослан муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе |

Комиссия әгъзалары:

| | |
|---|---|
| Фасхутдинов Рашит Шаукатович | Татарстан Республикасы Югары Ослан районы хәрби комиссары (килешү буенча) |
| Федотов Александр Николаевич | Югары Ослан муниципаль районы Яшьләр эшләре һәм спорт бүлеге башлыгы |
| Хусаинов Рашид Мукатдясович | «Югары Ослан район үзәк хастаханәсе» ДАССО Баш табибның поликлиника эше буенча урынбасары (килешү буенча) |
| Касимов Вилен Вакифович | Югары Ослан муниципаль районының «Мәгариф бүлеге» МКУ җитәкчесе |
| Гадельшин Ильгизар Анварович | МБГББУ «Матюшино урта гомуми белем бирү мәктәбе» «Хәрби хезмәт нигезләре» курсы укытучысы |
| Сиражетдинова Сания Ильмир кызы | Югары Ослан районы Хәрби комиссариатының (гражданнарны хәрби хезмәткә әзерләү һәм озату буенча) бүлек башлыгы (килешү буенча) |

Башкарма комитетның эшләр идарәчесе А.К. Мингазова

Югары Ослан муниципаль районы
Башкарма комитет җитәкчесенең
01.08.2019, № 720 карарына
Кушымта № 3

Россия Федерациясе Кораллы көчләре өчен
белгечләр әзерләүне контрольдә тоту буенча комиссия
СОСТАВЫ

Комиссия рәисе:

| | |
|---|---|
| Фасхутдинов Рашит Шаукатович | Татарстан Республикасы Югары Ослан районы хәрби комиссары (килешү буенча) |

Комиссия рәисе урынбасары:

| | |
|---|---|
| Сиражетдинова Сания Ильмир кызы | Югары Ослан районы Хәрби комиссариатының (гражданнарны хәрби хезмәткә әзерләү һәм озату буенча) бүлек башлыгы (килешү буенча) |

Комиссия әгъзалары:

| | |
|---|---|
| Федотов Александр Николаевич | Югары Ослан муниципаль районы Яшьләр эшләре һәм спорт бүлеге башлыгы |
| Касимов Вилен Вакифович | Югары Ослан муниципаль районының «Мәгариф бүлеге» МКУ җитәкчесе |

Башкарма комитетның эшләр идарәчесе А.К. Мингазова